СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,42319

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРы

2019 елның «16» декабреннән № 55-344

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында»

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, тоту һәм күзәтүчесез хайваннарны тоту, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2019 елның 16 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турында 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтләре» турындагы 4 бүлегенең 4.1 пунктындагы 8 пунктчасында «җирлек территориясендә яшәүче күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру» сүзләрен «хуҗасыз хайваннар белән эш иткәндә чаралар оештыру» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының "Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В. М. Козлов